ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а нче йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**06 май 2019 ел** **Олы Әшнәк ав.** **№ 12**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл жирлегендә жирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Жирләү һәм мәет кую эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына, "Татарстан Республикасында "Жирләү һәм мәет кую эше турында" Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында" 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пунктына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл жирлегендә мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә,

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл жирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28А йорт; Кече Әшнәк авылы, Красноармейская урамы, 32А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнен жаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл жирлеге башлыгы Р.А.Хөснетдинова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Олы Әшнәк авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның  6 маендагы
12  номерлы карарына
кушымта  №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлегендә**
**2019 елның 1 февраленнән  мәет кую буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1697 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетен) зиратка (крематорийга) күчерү (илтү) | 929 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру,  соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,47 |
| Барлыгы: | 5946,47 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Әшнәк авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 6 маендагы
12 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган бүтән зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 468 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1229 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетен) зиратка алып бару (илтү) | 929 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |